КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 июль г.Казань № 706

2022 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм төзелеш максатларында кулланыла торган гомумтаралган файдалы казылмалары булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланганда рөхсәт бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда Россия Федерациясендә рөхсәт бирү эшчәнлеге үзенчәлекләре турында» 2022 елның 12 мартындагы 353 номерлы карарының 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2022 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм төзелеш максатларында кулланыла торган гомумтаралган файдалы казылмалары булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланганда рөхсәт бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен (карарга теркәлә) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 22 июль, 706 нчы
карары белән расланды

## 2022 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм төзелеш максатларында кулланыла торган гомумтаралган файдалы казылмалары булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланганда рөхсәт бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

1. 2022 елның 31 декабренә кадәрге чорда Җир асты байлыкларыннан файдалану федераль агентлыгының «Гомумтаралган файдалы казылмалары булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлекләрен әзерләү, карап тикшерү, килештерү яки мондый исемлекләрне килештерүдән баш тарту тәртибен раслау турында» 2020 елның 6 октябрендәге 428 номерлы боерыгы белән расланган Гомумтаралган файдалы казылмалары булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлекләрен әзерләү, карап тикшерү, килештерү яки мондый исемлекләрне килештерүдән баш тарту тәртибендә каралган Татарстан Республикасы буенча җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлеген әзерләү срогы 17 эш көненнән артмаска тиеш, шул исәптән:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Вәкаләтле орган) тарафыннан җир асты байлыклары кишәрлеген Исемлеккә кертү турындагы заявканы (мөрәҗәгатьне) тикшерү процедуралары һәм карап тикшерү өчен Россия Федерациясе Оборона министрлыгына, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгына, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына – федераль, җирле әһәмияттәге яки төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре һәм оборона, куркынычсызлык җирләре булуга карата һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучыга – җир асты байлыклары кишәрлеген Исемлеккә кертү өчен аның ризалык бирүенә карата (әгәр Исемлек проектына кертелергә тәкъдим ителә торган җир асты байлыклары кишәрлеге файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлеге чикләрендә урнашкан һәм гариза бирүче тарафыннан мондый җир асты байлыкларыннан файдалануга ризалык бирелмәгән булса) рәсми сораулар җибәрү срогы ике эш көненнән артмаска тиеш;

Россия Федерациясе башкарма хакимиятенең федераль органнары, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты килештерүләрен, Вәкаләтле органның Исемлек проектын әзерләвен, килештерү өчен Исемлек проекты Вәкаләтле орган тарафыннан Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаментына җибәрелүен исәпкә алып, Исемлеккә кертү турындагы заявканы карап тикшерү процедуралары срогы барысы бергә бер эш көненнән артмаска тиеш;

Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаменты тарафыннан килештерелгән Исемлек проектын Вәкаләтле орган тарафыннан раслау процедурасы срогы бер эш көненнән артмаска тиеш;

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан Вәкаләтле органның Исемлекне раслау турындагы боерыгын дәүләт теркәвенә алу процедурасы срогы бер эш көненнән артмаска тиеш;

Вәкаләтле органның расланган Исемлекне заявка бирүчегә җибәрү процедурасы срогы бер эш көненнән артмаска тиеш.

2. 2022 елның 31 декабренә кадәрге чорда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына аукцион үткәрү турында игълан ителгәннән алып аның нәтиҗәләре буенча җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын бирү турында карар кабул ителгәнгә кадәр срок җиде эш көненнән артмаска тиеш.

3. 2022 елның 31 декабренә кадәрге чорда Вәкаләтле орган тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалары булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану лицензиясен рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү срогы җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен заявка бирүче тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының $333^{33}$ статьясындагы 1 пунктының 92 пунктындагы икенче абзацында каралган дәүләт пошлинасы һәм бер тапкыр түләнә торган түләүнең соңгы күләме түләнгән датадан алып бер эш көненнән артмаска тиеш.

4. 2022 елның 31 декабренә кадәрге чорда рәсмиләштерелә торган лицензиядә, гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларының сәнәгатьтә сынау эшкәртмәсе проектына таянып, бер үк вакытта гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын эшләп, бер ел эчендә җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясе һәм геологик разведка эшләре проекты нигезендә геологик разведка эшләрен үткәрү турындагы шартларны һәм гомумтаралган файдалы казылмалар запасларын исәпләп чыгару нәтиҗәсен күрсәтергә рөхсәт ителә.

5. 2022 елның 31 декабренә кадәрге чорда Вәкаләтле орган тарафыннан файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, гомумтаралган файдалы казылмалары булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре буенча файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасын үткәрү срогы җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан материаллар дәүләт экспертизасына тапшырылган датадан алып биш эш көненнән артмаска тиеш.

6. 2022 елның 31 декабренә кадәрге чорда Вәкаләтле орган тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларының сәнәгатьтә сынау эшкәртмәсе проектын килештергәндә аны карап тикшерү срогы җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан проект килештерүгә бирелгән датадан алып биш эш көненнән артмаска тиеш.

7. 2022 елның 31 декабренә кадәрге чорда Вәкаләтле орган төзегән комиссия тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү, гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү турында таныклык бирү срогы гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләүгә, гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү

турында таныклык бирүгә заявка бирелгән датадан алып ике эш көненнән артмаска тиеш.

8. 2022 елның 31 декабренә кадәрге чорда Вәкаләтле орган тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу факты билгеләнгәндә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару өчен җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын бирү турындагы заявканы карап тикшерү срогы әлеге заявка бирелгән датадан алып өч эш көненнән артмаска тиеш.

---